**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6150**
**07.11.2022**

2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү чаралары турында» 2007 елның 14 декабрендәге 4940 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары карамагындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга норматив чыгымнарны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә белем бирү оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында каралган белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарына туры китереп тәэмин итәргә.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2022 елның 7 ноябрендәге
6150 номерлы карарына
кушымта

2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
гомуми белем бирү оешмалары карамагындагы интернатларда
һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга
норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокациясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы карамагындагы интернат | шәһәр җирлеге | 104308 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 154787 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева